**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ КАМСКО-УСТЬИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ КАМА ТАМАГЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

ул. Калинина, д.31,
пгт. Камское Устье, 422820

Калинин урамы, 31 йорт,
штп. Кама Тамагы, 422820

тел.: (884377) 2-18-85, факс: 2-20-70, e-mail: Kamuste.Ispolkom@tatar.ru, http://kamskoye-ustye.tatarstan.ru.

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

27.04.2021 № 403

Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының җирдән файдалану һәм авыл җирлекләрендә төзелеш алып бару кагыйдәләре проектларын әзерләү комиссиясен төзү турында

Россия Федерациясенең 2004 елның 29 декабрендәге 190-ФЗ номерлы Шәһәр төзелеше кодексы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында шәһәр төзелеше эшчәнлеге турында» 2010 елның 25 декабрендәге 98-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Җирдән файдалану һәм авыл җирлекләре төзү кагыйдәләренең проектларын әзерләү комиссиясен 1 нче кушымта нигезендә төзергә.
2. Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Җирдән файдалану һәм авыл җирлекләрендә төзелеш кагыйдәләре проектларын әзерләү комиссиясе турындагы Нигезләмәне (2 нче кушымта) расларга.
3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) "Интернет" мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Кама Тамагы муниципаль районының рәсми сайтында (http:/ http://kamskoye-ustye.tatarstan.ru/) урнаштырырга.
4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Кама Тамагы муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесенең төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалык буенча беренче урынбасары А.М. Шәрәфиевка йөкләргә.

Җитәкче Р.М. Зәһидуллин

Кама Тамагы муниципаль
районы Башкарма комитетының
2021 елның 27 апрелендәге 403
номерлы карарына 1 нче
кушымта

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ КАМА ТАМАГЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ АВЫЛ ҖИРЛЕКЛӘРЕНДӘ ҖИРДӘН ФАЙДАЛАНУ ҺӘМ ТӨЗЕЛЕШ КАГЫЙДӘЛӘРЕ ПРОЕКТЛАРЫН ӘЗЕРЛӘҮ КОМИССИЯСЕ СОСТАВЫ**

| | |
|---|---|
| Заһидуллин Р. М | Кама Тамагы муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесе, комиссия рәисе; |
| Шәрәфиев А.М. | Кама Тамагы муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесенең төзелеш һәм ТКХ буенча беренче урынбасары, комиссия рәисе урынбасары; |
| Мөхәммәдуллина Ф.М. | Кама Тамагы муниципаль районы башкарма комитетының инфраструктура үсеше бүлеге башлыгы урынбасары, комиссия секретаре; |
| Комиссия әгъзалары: | |
| Идрисова Л.И. | Кама Тамагы муниципаль районы Советы аппаратының юридик бүлеге башлыгы (килешү буенча); |
| Головин С.В. | Кама Тамагы муниципаль районының мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы рәисе (килешү буенча); |
| | Территориясенә карата проект эшләнә торган авыл җирлеге башлыгы (килешү буенча). |

Кама Тамагы муниципаль
районы Башкарма комитетының
2021 елның 27 апрелендәге 403
номерлы карарына 2 нче
кушымта

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ КАМА ТАМАГЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ АВЫЛ ҖИРЛЕКЛӘРЕНДӘ ҖИРДӘН ФАЙДАЛАНУ ҺӘМ ТӨЗЕЛЕШ КАГЫЙДӘЛӘРЕ ПРОЕКТЛАРЫН ӘЗЕРЛӘҮ КОМИССИЯСЕ ТУРЫНДА НИГЕЗЛӘМӘ**

## 1. Гомуми нигезләмәләр

«Кама Тамагы муниципаль районы» муниципаль берәмлеге территориясендә җирдән файдалануны һәм төзелешне җайга салу системасының эзлекле камилләштерелүен һәм нәтиҗәле эшләвен тәэмин итү өчен Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы авыл җирлекләренең җирдән файдалану һәм төзелешләр кагыйдәләре проектларын әзерләү комиссиясе (алга таба - Комиссия) төзелә.

Комиссия Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы башкарма комитеты карары нигезендә төзелә.

Комиссия даими эшли һәм үз эшчәнлеген әлеге Нигезләмә нигезендә һәм 2004 елның 29 декабрендәге 190-ФЗ номерлы Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы нигезендә гамәлгә ашыра.

## 2. Комиссия составы

2.1. Комиссия составы Кама Тамагы муниципаль районы башкарма комитеты карары белән раслана.

2.2. Комиссия рәисе булмаганда аның вазыйфаларын Комиссия рәисе урынбасары башкара.

## 3. Комиссия компетенциясе

3.1. Комиссия компетенциясенә түбәндәгеләр керә:

3.1.1.Җирдән файдалануны һәм төзелешне җайга салу системасын эзлекле рәвештә камилләштерү процессын оештыру, шул исәптән җирдән файдалану һәм авыл җирлекләрен төзү кагыйдәләренә үзгәрешләр проектын эшләү, ә киләчәктә аларны гамәлгә ашыру;

3.1.2. Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Җирдән файдалану һәм авыл җирлекләрендә төзелеш кагыйдәләре проектын эшләүгә бәйле рәвештә гражданнарның һәм юридик затларның тәкъдимнәрен карау;

3.1.3. Иҗтимагый фикер алышулар нәтиҗәләре буенча бәяләмә бирү, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы нигезендә Кама Тамагы муниципаль районы Башлыгына рекомендацияләр әзерләү һәм аларны җибәрү.

## 4. Комиссиянең эшчәнлек тәртибе

4.1. Комиссия кирәк саен җыела, ләкин кимендә аена бер тапкыр.

4.2. Комиссия утырышы, әгәр анда Комиссия әгъзаларының билгеләнгән саныннан кимендә өчтән икесе катнашса, хокуклы дип санала.

4.3. Комиссия карары шунда булган комиссия әгъзаларыннан гади күпчелек тавыш белән кабул ителә. Тавышлар тигез булганда, рәис тавышы хәлиткеч булып тора.

4.4. Гражданнарның һәм юридик затларның тәкъдимнәре Комиссия рәисе исеменә җибәрелә. Комиссия рәисе аларны карау өчен ике атна дәвамында Комиссия утырышларында тәэмин итә.

4.5. Күрсәтелгән тәкъдимнәрне карау нәтиҗәләре буенча беркетмәдә чагыла торган карар кабул ителә.